ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.03.2022 № 377

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп җыела торган объектлар (территорияләр) исемлеген раслау турында» 2015 елның 19 июнендәге 684 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Полиция тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле кешеләр һәм объектлар (территорияләр) күпләп була торган урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) террорчылыкка каршы якланыуына таләпләрне һәм мондый урыннарның һәм объектларның (территорияләрнең) иминлеге паспортлары рәвешләрен раслау турында» 2015 елның 25 мартындагы 272 номерлы карары һәм Алабуга муниципаль районы җирле үзидарә органнарынына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча шәһәр җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турындагы килешү нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп җыела торган объектлар (территорияләр) исемлеген раслау турында» 2015 елның 19 июнендәге 684 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә һәм Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп җыела торган объектлар (территорияләр) исемлеген кушымта итеп бирелгән яңа редакциядә расларга.

2. «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп җыела торган объектлар (территорияләр) исемлеген раслау турында» 2015 елның 19 июнендәге 684 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 29 июлендәге 1074 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының
29.03.2022 № 377

карарына 1 нче кушымта

Алабуга муниципаль районы территориясендә урнашкан кешеләр күпләп җыела торган объектлар (территорияләр) исемлеге

| № | Объектның исеме (территориясе) | Урнашу урыны (адресы) |
|---|---|---|
| 1. | «Майдан» шәһәр тамаша үзәге | Алабуга шәһәре, Шишкин урамы, 80 |
| 2. | Пионерлар паркы | Алабуга шәһәре, Разведчиклар урамы |
| 3. | «Чебурашка» паркы | Алабуга, Нефтьчеләр проспекты, 26 |
| 4. | «Макдоналдс» тиз туклану рестораны | Алабуга шәһәре, Нефтьчеләр проспекты, 28 |
| 5. | «Городище» рестораны | Алабуга шәһәре, Тынычлык проспекты, 2 г |
| 6. | «Манхеттен» күңел ачу комплексы | Алабуга шәһәре, Интернационал урамы, 16 |
| 7. | «Алабуга» СҖТ МИЗ | Алабуга районы, махсус икътисадый зона территориясе, «Алабуга», Ш-2 ур., 4/1 корп. |
| 8. | «Йорт янында бакча» скверы | Алабуга шәһәре, Автомобильчеләр урамы |
| 9. | «Татар бистәсе» гаилә комплексы /«Гаилә мунчасы» | Алабуга шәһәре, Чапаев урамы, 72а |